ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

"03" октябрь 2023ел Калмия авылы №15

**"Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Калмия авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы "Калмия авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Калмия авылында 2023 елның 13 октябрендә 14.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Калмия авыл җирлегенең Калмия авылы территориясендә 2023 елда балигъ булган, Калмия авыл җирлегенең Калмия авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (Ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калмия авылы, Молодежная урамы , 23 йорты адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Калмия авыл җирлеге
Башлыгы Р.Ә. Гарипов